## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл жирлеге Заречье торак пунктында гражданнар дан үзара салым кертү турында

**26 ноябрь 2020 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-03 номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Заречье торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

2021 елда 1 төркем инвалидлар, Беек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Беек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, кендезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Заречье торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә узара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Заречье торак пункты Үзәк урамы буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (асфальт-бетон өслекле юлларның чокырларын ямау);
- Заречье торак пунктында тракторчыга карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәт курсәтүгә түләү (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 кен эчендә, Вахитов авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы И.Б. Бохарова

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВАХИТОВ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ВАХИТОВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ